Управление образования Исполнительного комитета муниципального образования г. Казани
Муниципальное бюджетное учреждение дополнительного образования «Центр дополнительного образования детей «Заречье» Кировского района г. Казани

# План-конспект открытого занятия на тему: «Су буенда кечке уен»

Объединение «Музыкальный татарский фольклор»
Педагог дополнительного образования
первой квалификационной категории
Залялеева Айгуль Ильгисовна

Казань, 2021

План – конспект

открытого занятия по фольклору

в форме фольклорной композиции «Су буенда кичке уен»

*Цель: Проверка полученных знаний.*

*Задачи:*

- сформировать положительную мотивацию к изучению татарского фольклора;
- развить творческие способности детей.
- формировать исполнительские навыки в области пения, движения;
- развить активное восприятие музыки посредством музыкального фольклора;
- воспитывать любовь к татарской народной культуре.

*Оформление:*

Зал оформляется атрибутами татарского народного быта. Ведушие в национальных костюмах.

**Ход урока:**

1. **Организация урока**
2. **Актуализация**

Дети встают, приветствуют всех с песней «Ассаламагалейкум» (Приветствие).

**Основная часть:**

***Педагог:*** Здравствуйте, ребята. Сегодня у нас будет необыкновенное музыкальное занятие. Сегодня мы побываем в гостях в татарской деревне. Игра – наиболее доступный для детей вид деятельности. В игре ярко проявляются особенности мышления и воображения ребёнка, его эмоциональность, активность, развивающаяся потребность в общении. В татарских сёлах и городах среди молодёжи были широко распространены игры подвижного характера. Без них не обходился ни один даже самый скромный народный праздник. В игру вовлекались целые группы подростков, которые состязались в силе, ловкости, быстроте, меткости. В связи с тем, что игры, как правило, проводились на улице, на свежем воздухе, это способствовало укреплению здоровья. Татарские народные игры являются неотъемлемой частью интернационального художественного и физического воспитания школьников. Радость движения сочетается с духовным обогащением детей. У них формируется устойчивое, заинтересованное, уважительное отношение к культуре родной страны. Создаётся эмоционально положительная основа для патриотического воспитания.

Постановка фольклорной композиции. Сценарий прилагается.

“Су буенда кичке уен”

Кичке уеннар элек-электэн татар халкының иң матур, иң күркәм йолаларыннан саналган. Җәйге матур кичләрдә, кояш баткач, картлар яткач,су буйлары, урман аланнары, ямь-яшел болыннар яшьләрнең шат авазларына күмелгән. Кичке уеннарда җыр-бию, уен-көлке бер генә минутка да тынып тормаган. Анда җырлы-биюле түгәрәк уеннары, ике урам арасында

жыр ярышлары, шаян такмаклар әйтешү, күмәк һәм ялгыз биюләр,кызыклы уеннар уйналган.Кичке уеннарда егетләр һәм кызлар бер-берсе белән танышкан-кавышканнар,күрешкән-сөешкәннәр, вәгъдәләр бирешкәннәр. Шуңа күрә дә кичке уеннар яшьләрнең иң яраткан урыны булып саналган. Гомумән хәзер традицион халык уеннарының актив кулланыштан китүе ачык күренә. Әгәр дә без киләчәк буыннарны милли традицияләрдә тәрбияләү зарурлыгын таныйбыз икән, халык рухының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән уеннарыбызның югалуына юл куймаска тиешбез. Уен ул – катнаш сәнгать һәм мәдәният төре, аның байтагында көй, бию, махсус җайланмалар катнаша.

Максат:
1)Балаларның җырлы-моңлы , биюле уеннары аша гасырлар буенча үткәрелгән татар халык йола бәйрәмнәрен саклап калу;
2) Киләчәк буынны милли традицияләр нигезендә тәрбияләү;
3) Уен барышында җанлы диалог, һәртөрле сөйләшүләр, көлке, җыр, сүз, импровизация аша балаларның сөйләм телен үстерү, мантыйкый (логик) фикерләвен арттыру;
Бурычлар:
1) Балаларны уен аша татар халык йолалары белән таныштыру;
2) Киләчәк буыннарны милли традицияләрдә тәрбияләү нигезендә халкыбыз рухының аерылгысыз бер өлешен тәшкил иткән уеннарыбызның югалуына юл куймау;

1 кыз:
Кумәк бию, уен көлке
Була кичке уенда.
Кызлар -егетләр жыела,
Таллыкта, су буенда.
2 кыз:
Пар табыш лы, эсир алыш
Кичке уенда була
Таныштыра, дуслаштыра
Яшьләрне шушы йола.
3 кыз:
Жырлар, биюләр өзелмәс.
Шатлык өстәр гармун да.
Укенерсез килмәсәгез,
Кызык булачак монда!

4 кыз: Кызлар! Әйдәгез, Лилияне кичке уенга чакырабыз.
Барысы: Әйдәгез!
5 кыз: Лилия кичке уенга чыгасыңмы?

6 кыз: (Лилия тәрәзәдән карый һәм әкрен генә:) Хәзер чыгам. (чыга)
Исәнмесез кызлар!
Кызлар: Исәнме Лилия.
(Марсель кинәт килеп чыга, калганнар аның артыннан.)
Малайлар: А-ХААААА!!!! ( Кызлар куркып китәләр)
1 егет: Исәнмесез, саумысыз!
Нигә кәҗә саумыйсыз.
2 егет: Әтәчегез күкәй салган
Нигә чыгып алмыйсыз.
7 кыз: Әй, Әпсәлам, Әпсәләм!
Сәлам бирдем әссәлам!
Сездән безгә тиештер бит.. Вәгаләйкемәссәлам!!!

Малайлар: Сәлам!
Барысы кызлар: Шуннан.
3 егет: Тугыз ким уннан.
Барысы кызлар: Шуннан.
4 егет: Утырган да шуган.
Барысы кызлар: Шуннан.
5 егет: Кишер белән суган..
Барысы кызлар: Шуннан?
6 егет: (аптырап) Егетләр, ярдәм итегез әле миңа!

Алып баручы: Кызлар,егетләр әйдәгез уйнап алыйк.

- Йөзек салыш уены:
- Жыр: "Ашхабад",
- Әтәч булып кычкыру,
- Курайда уйнау,
- Шигырь сөйләү,

(Егетләр кул селтиләр. Җырларга җыеналар, бер-берсенә капма-каршы басалар.)
7 егет: Эй, егетләр,кызлар, әйдәгез әле, жырлап алыйк!

"Әнисә" җыры.

7 кыз: Әйдәгез уеннар уйныйбыз .
Барысы : Әйдәгез, әйдәгез.
1 кыз: Нинди уен уйныйбыз?

Барысы : " Капкалы уен"ын уйныйбыз
2 кыз:
Яңа утырткан капканы
Баганасы бик шома.
Капка эләктереп калмасын
Ычкынырга чамала.
(Егетләр, кызлар парлашып басалар,парлары белән капкадан чыгалар. Көй беткәндә кайсы пар уртада калса , шуларга җәза бирелә.) Бер кыз белән егет кулларын өскә күтәреп басалар, калганнар капкадан чыга башлый. Капкачылар кемнедер тотып калалар. Җәза бирәләр.
Татар бию көе.
3 кыз: Ниязны нишләтәбез?
Барысы : Мәзәк сөйләсен.
3 егет: Марсель: Юк, мин табышмак әйтәм.
Сырлы, сырлы, сырлы ул,
Безнең белән җырлый ул,

Биетә дә, җырлата дә,
Күңелле ул, моңлы ул.
Я, нәрсә ул, әйтеп карагыз
Барысы : Гармун.
4 юн: Ә гармунда кем остарак уйный, ягез әле,егетләр
(Нияз гармунда уйный татар җыры яки татар биюе. Калганнар парлап әйләнәләр).
4 кыз: Викторияне нишләтәбез?
5 егет: Җырласын.
Барысы: Юк, биесен

Балалар такмак әйтә.
Бие, бие, бие эле, биегәне юк эле
Биегәне булмаса да матур бии бит әле
.
Бергә сандугач-күгәрчен һәм матур гөл генә җырын җырлыйлар.

Уйнадык та, җырладык тә,
биедек тә! Әйдәгез кайтыйк инде.?
Барысы: Эй, кайтасы килми бит эле!
6 кыз: Кайтыйк инде, эни өйдә су көтә
Барысы бергә: Әйдәгез кайтыйк, бергә "Ак каен" җырын башкарып, китәләр.

**Подведение итогов урока**

Педагог: Мы с вами закрепили практические навыки и знания, исполнения народных песен, народных игр.
Спасибо всем за чудесный урок, до скорых встреч ребята.

Барысы : **"Такмак әйтеш"**
1)Без җырлыйбыз шаян җырлар,
Ә сез тыңлап торыгыз.
Әнә килә автомобиль,
Булыр безнең җырыбыз.
2) Әнә килә автомобиль ,
Төягәннәр калайлар.
Безнең авыл малайлары,
Туксан яшьлек бабайлар
Туксан яшьлек бабайлар. 2 тапкыр (артка китәләр)
3)Әнә килә автомобиль,
Төягәннәр капчыклар.
Безнең авылның кызлары,
Сиксән яшьлек карчыклар.
Сиксән яшьлек карчыклар. 2 тапкыр. (артка китәләр)
4. Барысы :
Тыпыр,тыпыр, тыпырдашып
Бергә басаек әле
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп,
Күңел ачаек әле.
Күңел ачаек әле.